КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1080

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында» 2016 ел, 14 март, 140 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында» 2016 ел, 14 март, 140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 343 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – » сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – » сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча);»;

10 пунктта:

дүртенче абзацта «үз кулы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган документ.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен әлеге Регламентның 10 пунктында күрсәтелгән документлар Комиссиягә кәгазьдә шәхсән тапшырыла йә почта элемтәсе аша 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт адресына яки mon@tatar.ru электрон почтасы аша pdf форматында җибәрелә. Тиешле документларның төп нөсхәләре дәгъва итүче тарафыннан сайлап алу чараларына килгәннән соң билгеләнгән тәртиптә күрсәтелә.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була.»;

әлеге Регламентка кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентына кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1080 нче карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры

______________________________
(инициаллары, фамилиясе)

______________________________
(фамилиясе, исеме)

______________________________,
(булганда атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшәүче

______________________________
(адресы)

______________________________
телефоны (эш, кәрәзле, E-mail)

Гариза

Миңа Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервына кертү өчен конкурста катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм

______________________________________________________________
(вазыйфа исеме)

______________________________________________________________

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламенты, шул исәптән вакантлы вазыйфага куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

______________________________________________________________
(теркәлә торган документларны күрсәтергә)

______________________________________________________________

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламенты белән таныштым, шәхси мәгълүматларым белән эш итүгә риза.

| ______________ | ______________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (датасы) | (имзасы) | (имзаны таркатып язы) |

______________________